**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18 ноябрь 2022 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 17 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2023 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; 90 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, мобилизация гаилә әгъзалары яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1)Чураш торак пунктындагы урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) Чураш торак пунктындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

3) Чураш авылы зираты өчен чапкыч сатып алу;

4) район газетасында некрологлар һәм юбилярларны котлаулар бастыру;

5) Чураш торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (бетон каркаслар сатып алу һәм урнаштыру,) ;

6) Чураш авылы мәдәният йорты өчен музыка аппаратурасы сатып алу;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 145 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 75 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 75 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2023 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы I төркем инвалидлардан; 90 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, мобилизация гаилә әгъзаларыннан тыш яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Чураш торак пунктындагы урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) Чураш торак пунктындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

3) Чураш авылы зираты өчен чапкыч сатып алу;

4) район газетасында некрологлар һәм юбилярларны котлаулар бастыру;

5) Чураш торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (бетон каркаслар сатып алу һәм урнаштыру,) ;

6) Чураш авылы мәдәният йорты өчен музыка аппаратурасы сатып алу;Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева